КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 17 апрель г.Казань № 298

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2017 ел, 15 декабрь, 996 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2017 ел, 15 декабрь, 996 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 26 февраль, 110 нчы; 2018 ел, 7 май, 327 нче; 2018 ел, 30 июль, 614 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1288 нче; 2019 ел, 23 апрель, 329 нчы, 2019 ел, 18 декабрь, 1165 нче, 2020 ел, 11 февраль, 87 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәнең 4.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле 4.3.13 пунктчасы өстәп, үзгәреш кертергә:

«4.3.13. Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының $20.6^1$ статьясында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзү.».

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була;

әлеге карарның гамәлдә булуы 2020 елның 6 апреленнән барлыкка килгән

хокук мөнәсәбәтләренә тарала.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин